**ГЛАВА**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2023 Кодаш авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча Әгерҗе муниципаль
районының Кодаш авыл җирлеге
Биектау торак пунктында гражданнар
җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башлыгы

1.2024 елның 21 ноябренә Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Биектау торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 10 сәг. 00 мин. гражданнар җыенын билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2025 елда үзара салым акчаларын кертү өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә килешәсезме? Укуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасыннан тыш:

1. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (сууткәргечне ремонтлау, су насослары сатып алу, су суырту манаралары, скважиналары һәм башка инженерлык корылмалары) проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны су белән

тээмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортлау һәм су белән тәэмин итү (суүткәргечне ремонтлау, су насосы сатып алу, тирән насослар сатып алу, һәм Биектау авылындагы су башнясы өчен башка материаллар һәм башка чыгымнар).

2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машиналарын тоту, ремонтлау, сатып алу; янгын автомашинасын йөртүчегә шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм башка чыгымнар).

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урамнарны кардан чистарту; үләнне чабып алу; дизель ягулыгы сатып алу; тракторчы килешүе буенча хезмәт өчен түләү, Мирная урамына вак таш сатып алу һәм башка чыгымнар).

“РИЗА” “КАРШЫ”

3.Адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Биектау авылы, Сәйдәш урамы, 2 йорт, авыл клубында гражданнар җыенын үткәрергә.

4.Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кудаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең (https://www.agryz.tatarstan.ru) порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы
Ф.М.Шакиров